

Мордовия Главасы Артём Здунов рәислегендә милләтара һәм конфессияара монәсәбәтләр буенча Совет утырышында предметлы фикер алышу - яшьләр арасында радикаль милләтчелек идеологиясенә һәм экстремистик идеяләргә каршы торунын актуаль мәсьәләләре, шулай ук чит ил гражданнарынын социаль һәм мәдәни адаптациясе буенча узды.       Мордовия Главасы билгеләп vткәнчә, бу эшнен әһәмиятен Россия Президенты Владимир Путин берничә тапкыр ассызыклады. Бигрәк тә ул махсус хәрби операция шартларында моһим – хәзер ул милли куркынычсызлыкнын стратегик мәсьәләләре белән бер рәттә тора торган тобәкләрдәге тотрыклылыкнын моһим факторы.

«Россия и Мордовия, как ее неотъемлемая часть, – дом для всех народов. И в нашем многонациональном обществе принципиальное значение имеют сплоченность людей, поддержка Отечества на всех фронтах, уважение к традициям и культуре нашей великой страны, - диде Артём Здунов. – В условиях вызовов, связанных с попытками дестабилизации межнациональных и межконфессиональных отношений в субъектах нашей страны, особую актуальность приобретают вопросы адаптации иностранных граждан. И то, что открытых конфликтов между представителями разных национальностей и конфессий в нашей республике нет, не значит, что все спокойно. Есть факторы, которые могут способствовать потенциальному росту межнационального напряжения. Мы не должны этого допустить!»

Бу мәсьәләләрне хәл итvгә хакимиятнен барлык органнары, гражданлык жәмгыяте институтлары һәм хокук саклау органнары тарафыннан системалы һәм эзлекле рәвештә якын килергә кирәклеге билгеләп vтелде. Аерым категория - яшьләр. Яшьләр арасында алып барыла торган эш турында Яшьләр эшләре буенча дәvләт комитеты рәисе (Председатель Государственного комитета по делам молодежи РМ) Анастасия Гришнева сойләде. Ул билгеләп vткәнчә, хәзер аеруча куркыныч интернет-кинлектән һәм социаль челтәрләрдән килә – алар аноним аралашунын чикләнмәгән момкинлеген бирә. Деструктив контентны ачыклау, булдырмау очен мәгълvмати куркынычсызлык Үзәге булдырылды һәм эшли, яшьләр белән ата-аналар жәмәгатьчелеге арасында “Куркынычсыз интернет” темасына мәгълvмати кампанияләр уздырыла. Яшьләр һәм балалар хәрәкәтенә ярдәм итv, традицион кыйммәтләр тәрбияләv, яшvсмерләр арасында спортны популярлаштыру элеккечә топ профилактика булып кала. Моһим юнәлеш - яшьләр арасында халыкара хезмәттәшлек. Нәкъ менә шуна кvрә хәзер чит ил студентлары очен яшьләр оешмаларын vстерvгә зур игътибар бирелә, халыкара дуслык

клубы эшли.
Мәгариф олкәсендә дә шундый ук эш алып барыла. Анын турында Мордовия мәгариф министры Елена Солдатова сойләде. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә һәм урта һонәри белем бирv учреждениеләрендә хәзер чит ил гражданнарынын 145 баласы белем ала. Сонгы елда бу сан сизелерлек vзгәрмәгән. Мондый балаларны жайлаштыруда топ проблема – рус телен белмәv яки начар белv, дип билгеләп vтте Елена Петровна. Республикада бу юнәлештә унышлы эшчәнлек алып барылган - Мордовиянен рус теле туган теле булмаган балалар белән эшләv тәжрибәсе башка тобәкләрдә дә кинәя. Коллиятләрдә һәм техникумнарда «студент-студентка» моделе кулланыла. Йоз процент бала Россиянен тарихи даталарына бәйле чараларга жәлеп ителгән, остәмә белем алган.
Н.П.Огарев һәм М.Е.Евсевьев исемнәрендәге университетларыбызда чит ил студентларын адаптацияләvдәге vз эшләнмәләре турында сойләделәр. МГУда хәзер 3700 гә якын чит ил студенты укыса, МГПУда – 89. Ике вузда да тулы бер система тозелгән: рус телен белv сыйфатын яхшырту буенча остәмә дәресләр, патриотик, спорт һәм мәдәни чаралар vткәрелә, мәдәният vзәкләре булдырылган, яшьләр фәнни-тикшеренv эшчәнлегенә жәлеп ителә. Педагогика университетында чит ил студентларына психологик ярдәм кvрсәтv vзәге булдырылган, ә МГУда - чит ил кешеләрен рус теленә ойрәтv буенча ил вузлары санына кергән.
Мордовия Главасы мондый алымны хуплады: ин моһиме - яшьләрнен дорес, файдалы эшләр белән мәшгуль булулары.
Мигрантларны эшкә урнаштыру һәм аларнын социаль, мәдәни адаптациясе турында Мордовия социаль яклау, хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итv министры Игорь Князьков, шулай ук Мордовия мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министрынын беренче урынбасары Александр Кочеваткин сойләделәр.
Муниципалитетларда милләтара һәм конфессияара монәсәбәтләр олкәсендәге эшкә аерым игътибар бирелде. Мордовия Республикасы Главасы администрациясе һәм Мордовия Республикасы Хокvмәте житәкчесе, Совет рәисе урынбасары Булат Хәйретдинов билгеләп vткәнчә, жәмгыятьтәге вәзгыятьне тотрыксызландыру омтылышлары дустанә булмаган илләрдән башлана. Гражданнар бу йогынтыга дучар ителә, аларны яллыйлар; еш кына бу конкvреш конфликтларыннан башлана. «Бу провокацияләргә һич тә бирешергә ярамый! - дип ассызыклады ул. - Гомумән алганда, тобәктә милләтара һәм конфессияара монәсәбәтләр олкәсендә вәзгыять тыныч һәм унай, әмма бу йомшарырга сәбәп тvгел. Әлеге юнәлештә зур эш котә.»
Утырыш азагында беркетмә карары һәм эш планы расланды.

**Наилә НАСЫРОВА**